РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

__25.06.2025__ **Чистай шәһәре** **№__127__**

Чистай шәһәр Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын аукцион үткәрмичә генә урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 27 декабрендәге 206 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен әзерләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Чистай шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәр Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын аукцион үткәрмичә урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 27 декабрендәге 206 номерлы карарына түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.5.1 пунктының 1 пунктчасында «Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең кисәтү (проактив) режимында очрагын һәм тәртибен» 6 бүлеген өстәргә.

1.3. 6 бүлеккә «Муниципаль хезмәтне кисәтү (проактив) режимда күрсәтү каралмаган» 6.1 пунктын өстәргә.

1.4. 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелгән гарызнамәне формаль-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал сорауның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны

бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә».

2. 2 бүлектә «муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә, кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган (бирелә торган) документ (документлар) турында белешмәләр таләп ителми» 2.10 пунктын үз көчен югалктан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.Р. Хаматов